Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение "Алабердинская средняя общеобразовательная школа" Тетюшского муниципального района РТ

«Рассмотрено»	«Согласовано»	«Утверждаю»
Руководитель МО _____/З.Г.Сулейманова./ Протокол № 1 от «25» августа 2022г.	Заместитель директора по УВР МБОУ «Алабердинская средняя общеобразовательная школа» _____/Р.Г.Шайхутдинов/ «27» августа 2022г.	Директор МБОУ «Алабердинская средняя общеобразовательная школа» _____/В.Ю.Гарифуллин/ Приказ № 67 от «29» августа 2022г.

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

по Родному языку (татарский язык) в 4 классе
учителя начальных классов
I квалификационной категории
МБОУ «Алабердинская средняя общеобразовательная школа»
Нигматуллиной Люции Равиловны

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1 от «29» августа 2022 г.

2022– 2023 учебный год

Предмет: Туган тел (татар теле)
Укытучы : Нигъмәтуллина Люция Равил кызы.
Сыйныф: 4
Программа материалы үтү өчен-102 сәгать
Атналык сәгатьләр саны:3

Аңлатма язуы

<u>4 нче сыйныф өчен татар теле фәненнән эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:</u>

1. РФ һәм ТР “Мәгариф турындагы Закон” ына;

2.. Приказ 09.07.2012 №4154/12 “Об утерждении базисного и примерных учебных планов, для образовательных учреждении РТ, реализующих программы начального общего образования.;

3. Информационное письмо МО и Н РТ от 23 июня 2012 года №7699/12 « Об учебных планах для 1-9 классов школ РТ реализующих основные образовательные программы начального общего образования и основного общего образования с ФГОС общего образования «(4 модель)

4. 06.10.2009 нчы елда РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган “Гомуми башлангыч белем бирү федераль дәүләт стандартын гамәлгә кертү” турындагы боерыгына (Приказ №373);

5. МБГББУ “Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Алабирде гомуми урта белем бирү мәктәбе” нең 2022 – 2023инче уку елына төзелгән укыту планына;

6. Белем бирү учреждениеләрендә укыту процессында куллану өчен рөхсәт ителгән “Перспективалы башлангыч мәктәп” концепциясе һәм белем бирүнең яңа стандартлары таләпләренә туры килгән һәм рөхсәт ителгән региональ дәреслекләргә

- Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән дәреслек “Перспективалы башлангыч мәктәп” И.Х.Мияссарова, К.Ф Фәйзрахманова .

Татар теле фәнен тематик планлаштыруга аңлатма язуы.

Башлангыч гомуми белем бирүнең төп программасы федералҗ дәүләт белес стандартларын (Россия Федераөиясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы, № 373, 06.10.2009) аныклаучы һәм үстереп җибәрүче норматив документ булып тора.

Эш программасы структурасы. Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

Эш программасының эчтәлеге. Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”**. Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Татар теле укытуның **максаты: белемнәрне системага салу, тирәнәйтү, яңа мәгълүмат бирү, укучыларда әйтмә һәм язма сөйләмнәрен үстерү.**

Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы.

Тыңлап аңлау. Сөйләмдәге сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аңлау, аларны бер-берсеннән аеру. әйтелгән фикердәге мөһимрәк булган вакыйгаларың эзлеклелегенә төшенү.Тыңлый белүне уңышлы аралашуның шарты, кара-каршы сөйләшүнең нигезе икәнен үзләштерү.

Сөйләү. Сөйләм культурасын үстерү. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен гамәли үзләштерү. Укуга һәм көндәлек тормышка кагылышлы темалар буенча әңгәмә кору.Укылган текстка сорау кую, аның эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга җавап бирү, планын төзү. Укучыларга якынрак булган темалар буенча сөйләшү. Гадирәк җөмләләрдән төзелгән төрле темаларга кагылышлы монологик сөйләм оештыра белү, интонация үзенчәлекләрен үзләштерү. Сөйләм этикеты үрнәкләреннән дөрес файдалану.

Уку. Әкиятләрне, кечкенә хикәяләрне, дәреслектәге текстларны аңлап, дөрес, йөгерек итеп укый белү. Текстның төп фикерен аңлап, темасын билгели алу, кирәкле урыннарын сайлап уку. Гади план төзеп, текстның эчтәлеген сөйләү һәм укучының текстка мөнәсәбәтен белдерү.Укыганның эчтәлегенә, тел үзенчәлекләренә, төзелешенә бәя бирү. Информацияне аңлата һәм гомумиләштерә алу.

Язу. Язма сөйләм белән телдән сөйләмнең аермасы. Җөмләне текстан аера белү. Хат һәм төрле котлау текстлары язу. Өйрәнелгән кагыйдәләргә нигезләнеп текстларны күчереп, ишетеп язу.Үзлегеннән зур булмаган текстлар иҗат итү.

Программа атнага 3 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 102 сәгать. Шулардан контроль диктантлар – 4 ,сочинение- 4, изложение – 4 сәгать. Татар теленнән тематик план Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән дәреслек “Перспективалы башлангыч мәктәбе” И.Х.Мияссарова, К.Ф Фәйзрахманова нигезендә төзелде .

Укыту курсы темалары эчтәлеге:

1.1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.

Аваз һәм хәреф. Сузык һәм тартык авазлар.Иҗек.Сүзләрне юлдан юлга күчерү. ь,ъ хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.

Янәшә килгән бертөрле аваз хәрефләре булган сүзләр.Алфавит. Алфавитның әһәмияте.Сүзлекләр белән эш.Сингармонизм законы турында беренче күзаллау.

2. Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.Сүзнең лексик мәгънәсе .

Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Тотрыклы сүзтезмәләр, омоним, синоним антоним,фрозеологик әйтелмәләр сүзлеге белән эш. Күп мәгнәле сүзләр. Искергән һәм яңа сүзләр

3. Сүз төзелеше.

Кушымча.Кушымчаларның төрләре.Кушымчаларның ясагыч һәм төрләндергеч буенча ясалышы(кушма, парлы сүзләр)

4. Сүз төркемнәре . Исем.

Исем. Мәгънәсе, сораулары. Җөмләдәге роле Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр Ялгызлык исемнәрдә баш хәреф

Берлек һәм күплек сан формалары. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше.

5. Фигыль .

Мәгънәсе. Сораулары. Барлык, юклык формалары Зат-сан белән төрләнүе. Хәзерге, үткән, киләчәк заманнар. Фигыльләрнең күп мәгънәлеге.

Боерык фигыль. Фигыльнең нигезе дифтонгка тәмамлануы. (сау-савыйм, савыйк, савыгыз)

6. Сыйфат .

Мәгънәсе,сораулары. Җөмләдә роле. Сөйләмдә әһәмияте. Сыйфат дәрәҗәләре, сыйфатның җөмләдәге роле. (аергыч, хәбәр)

7. Алмашлык ..Зат алмашлыклары. Җөмләдәге һәм текстагы роле. Сорау алмашлыклары.Килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы.

8. Сан .

Санның билгеләмәсе, сорауларымикдар саны, тәртип саны.

9**. Рәвеш .**Лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен белдерүе.Аның төрләнмәве.Төп синтаксик функциясе – хәл.

10. Кисәкчәләр. Да. дә. гына , генә. Та, тә, ук, үк, кына ,кенә кисәкчәләре. Сөйләмдәге роле. Аларның җөмләгә төрле төсмер өстәве.

11. Бәйлекләр . Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә йомгак ясау, системалаштыру.

12. Җөмлә. Сүзтезмә .

Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәдәге иярүче һәм иярткүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү

13. Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр.

Җөмләнең баш кисәкләре.

14. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру.

15. Җөмләнең иярчен кисәкләре Аергыч . Аергычка билгеләмәне һәм аның белдерүен аңлату.

16. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең узара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнеше.Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

17 .Эндәш сүзләр. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре.

18. Гади һәм кушма җөмлә.

Тезмә кушма җөмләләрдә һәм, ә, ләкин, әмма теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре.

Укучыларның белем һәм күнекмәләренә төп таләпләр

Укучылар белергә тиеш:

-сүзнең мәгънәле кисәкләре: тамыр һәм кушымча, ясагыч кушымча, төрләндергеч кушымча;

- сүз төркемнәре: исем, сыйфат, фигыль, кисәкчә, бәйлек, рәвеш.
- җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, җөмләнең иярчен кисәкләре

Укучылар башкара алырга тиеш:

-үтелгән орфограммалар (калын һәм нечкә сузыклар, яңгырау һәм саңгырау тартыклар, парсыз тартыклар, нечкәлек һәм аеру билгеләре, кушма һәм парлы сүзләр, тамырда авазлар чиратлашуы, кисәкчәләр) кергән 75-80 сүзле текстны, җөмлә ахырында тиешле тыныш билгеләрен куеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп диктант итеп язу.
-текстларны грамоталы һәм каллиграфик дөрес күчереп язу.
- сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү(тамыр һәм кушымчаларны аеру, кушымчаларның төрен билгеләү, тамыр, ясалма, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү).
- сүз төркемнәрен һәм аларның грамматик билгеләрен тану, аеру (исемнең санын, килешен, фигыльнең затын, заманын);
- берлек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү
- фигыльне заман формаларына куя белү.
-текстта синонимнарны һәм антонимнарны таный, сөйләмдә куллана белү.
-сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләрнең бәйләнешен билгеләү, сүзтезмәләрне аеру; сүзтезмәдәге иярtүче һәм иярүче сүзләрне аеру.
- җөмлә тикшерү (төрен билгеләү, баш һәм иярчен кисәкләрне аера белү)
- бергәләп төзегән план буенча 90-95 сүзле изложение язу.
- текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.
- текстны мәгънәле кисәкләргә бүлү, кызыл юлны саклау.
- текстның мәгънәле кисәкләре, җөмләләр арасында бәйләнеш булдыру.
- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.

- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), сочинение язу.
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

4 нче сыйныф ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру программасын үзләштерү буенча планлаштырыла торган нәтиҗәләр

Башлангыч гомуми белем бирү баскычында татар теле фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә укучыларда белем алу осталыгы нигезе буларак **танып белү, коммуникатив, регулятив һәм шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре формалашачак.**

Танып белү универсаль уку гамәлләре

Укучылар өйрәнәчәк:

• мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
• күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;
• тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
• материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
• бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
• фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
• уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

• интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;
• мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү тө-зергә.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре

Укучылар өйрәнәчәк:

• партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
• нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
• килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
• сораулар формалаштырырга.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

• сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;
• монолог төзергә.

Регулятив универсаль уку гамәлләре

Укучылар өйрәнәчәк:

• таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерергә;
• гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
• кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
• максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
• сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

• партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;

• *уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;*
• *ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;*
• *яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.*

Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре

Укучыларда формалашачак:
• татар теле фәненә танып белү кызыксынуы;
• дәреслек геройларына һәм партадаш күршеңә ярдәм итү инициативасы;
• үз уңышларың/уңышсызлыкларыңның сәбәпләре турында фикер йөртү;
• нормалардан тайпылышны күрү;

ШУУГ- шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре **ТБУУГ- танып белү универсаль уку гамәлләре**

РУУГ- регулятив универсаль уку гамәлләре **КУУГ- коммуникатив универсаль уку гамәлләр**

Татар теленнән календарь – тематик план 4 класс

№	Дәреснең темасы	Сәг	Дәрес тибы	*Планлаштырыла торган нәтиҗәләр*		Өй эше	Үтәлү вакыты	
				предметлы	*Шәхсиятле һәм метапредметлы (УУГ формалаштыру)*		план	факт
1	2	3	4	5	6	7	8	9
1	1-3 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.	1	кереш	1-3 сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерү	ШУУГ: белү-белмәү чикләрен чамалау ТБУУГ:төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру, әйтелеш һәм язылышка караган орфограммаларны куллану, сүзләрне иҗеккә бүлү, юлдан-юлга	9 бит 3 нче күнегү	3.09	
2	Җәйге истәлекләр буенча сочинение язу.	1	катнаш			Җәйге истәлекләр буенча сочинение язу.	5.09	

3	Авазлар һәм хәрефләр.	1	катнаш	сүзләрдәге орфограммаларны танып, аларның язылышын кагыйдәгә нигезләнеп аңлату	күчерү“Аңлатмалы сүзлек”, “Дөрес яз” “Дөрес әйт”сүзлеге белән эш КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	Алфавитны искә төшер	8 .09	
4	Грамматик биремле диктант .Күбәләк малае Әлтәфи.	1	катнаш	Ишетеп язу күнекмәләрен камилләштерү.		10 нчы күнегү хәтер диктанты	10.09	
5	Тамыр һәм кушымча	1	катнаш	Тамырдаш сүзләрне табу		14 нче күнегү 14 бит.	12.09	
6	Сүз төркемнәре			Сүз төркемнәрен искә төшерү		17 нче күнегү 16 бит	15 .09	
7	1-3 сыйныфта үткәннәр буенча тест биреме №1	1	Белем күнекмәләрне тикшерү	Җөмләнең баш кисәкләрен табу, тест биремнәрен башкару		18 бит иҗади бирем	17 .09	
8	Аңлатмалы диктант. Көз якынлаша.	1		Җөмләләрне, сүзләрне дөрес яза белү күнекмәләрен үстерү		Көзге әкият иҗат ит	19 .09	
9	**Сүзнең лексик мәгънәсе**	1	катнаш	Лексик төшенчәсен аңлату,аңлатмалы сүзлекләр белән эш,хезмәтләрне бәяләү, төзәтү; татар теленең сүз байлыгы, сүзнең лексик мәгънәсе; лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу	ШУУГ: дәреслек геройларына ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү ТБУУГ: фәнни әдәбият белән эшли , үзеңнең күзәтүләреңне язмача билгели белү	Иҗади бирем. Кабан күле турында әкият яз	22.09	
10	Алынма сүзләр.	1	катнаш	әйтелеш һәм язылыш, сүзлек запасын тулыландыру.		32 нче күнегү 27 бит	24.09	
11	Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр.	1	белем һәм күнекне практикада куллану	Сүзләрнең төрле мәгънә белдерүе	ТБУУГ: Аңлатмалы сүзлек белән эш	дәфтәр 15 нче күнегү	26.0.9	
12	Тотрыклы сүзтезмәләр.	1	катнаш	Фразеологик әйтелмәләрне сөйләмдә	ШУУГ: дәреслек геройларына ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү	42 нче күнегү 32 бит	29. 09	

				куллану	ТБУУГ: Сүзлекләрне белешмә чыганагы итеп куллана белү			
13	Омонимнар	1	катнаш	Парларда эш,омонимнарны табу	ТБУУГ:сүзлек белән эшли; алынма сүзләрне, синоним, антоним исем, сыйфат фигыльләрне, омонимнарны текстта таный һәм сөйләмдә куллана; сүзнең төп һәм күчерелмә мәгънәләрен билгели	45 нче күнегү 33 бит	1.10	
14	Синонимнар, антонимнар.	1	практикада куллану			Эш дәфтәре 20, 21 нче күнегү	3.10	
15	Изложение язу. Усак.	1	катнаш	Укучыларның белем күнекмәләрен ныгыту	ШУУГ:алган белемнәрне кулланып, эзлекле рәвештә эчтәлекне бирә, изложение язу	Карточка биреме.	6.10	
16	**Сүзнең лексик мәгънәсе** темасы буенча тест биреме №2	1	белем һәм күнекмәләрне прак-тикада кул-лану		ТБУУГ: рәсем һәм план буенча биремнәр үтәү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	План буенча сочинение 52 нче күнегү	8.10	
17	Тамыр һәм кушымча.	1	кереш		КУУГ: сүзләрнең тамырын һәм кушымчасын билгели, әйтелешенә карап тиешле кушымча ялгый; тамырдаш сүзләр табу РУУГ: кагыйдә, алгоритм ярдәмендә бирем үтәлешенең дөреслеген тикшерү	56 нчы күнегү, дәфтәр 24 нче күнегү	10.10	
18	Сүз ясагыч кушымчалар.	1	яңа белем	Парларда эш,сүз байлыгы; төрле телләрдән кергән сүзләр, кулланылу өлкәсе		Дәфтәр 27 нче күнегү	13 .10	
19	Сүз ясагыч кушымчалар.	1	яңа белемнәр формалаш тыру	Модель буенча эш буенча эш	КУУГ**:**күршең белән хезмәттәшлек итү ТБУУГ: ясагыч һәм бәйләгеч кушымчаларны; тамыр, кушма, парлы сүзләрнең ясалышын, кушымчаларны кисәкчәләрдән аера белергә сүз ясагыч кушымчаларны аера	61 нче күнегү 42 бит	15.10	
20	Сюжетлы рәсем буенча сочинение. ”Җиләкле җәй”	1	кабатлау һәм ныгыту.	Рәсем һәм план буенча эш	РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	Дәфтәр 28 нче күнегү	17. 10	
21	Төрләндергеч кушымчалар.	1	яңа белемнәр формалаш тыру	Тартым, күплек һәм килеш кушымчалары	РУУГ: кагыйдә, алгоритм ярдәмендә бирем үтәлешенең дөреслеген тикшерү ШУУГ: дәреслек геройларына ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү	Дәфтәр 29, 30 нчы күнегү	20 .10	

22	Кушма сүзләр.	1	яңа белемнәр формалаштыру	ясалма сүзләр: кушма сүзләр, аларның ясалышы	ТБУУГ: сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү, кушымчаның төрен билгели; тамыр, ясалма, кушма, парлы сүзләрне, тезмә сүзләрне аерып күрсәтә, сөйләмдә куллана, дөрес яза төрләндергеч һәм сүз ясагыч кушымчаларны аеру РУУГ: кагыйдә ярдәмендә бирем үтәлешенең дөреслеген тикшерү	Дәфтәр 33 нче күнегү	22.10	
23	Кушма сүзләр.	1	ныгыту	Парларда эш,сүзләрнең мәгънәләре,		Дәфтәр 16 бит иҗади эш	24.10	
24	Парлы сүзләр.	1	ныгыту һәм гому-миләштерү	Парларда эш, парлы сүзләр, аларның ясалышы һәм дөрес язылышы		76 нчы күнегү 50 бит	27.10	
25	Тезмә сүзләр.	1	катнаш	Тезмә сүзләрне аеру, дөрес язу		Эш дәфтәре 36, 37 нче күнегү	7.11	
26	**Контроль диктант №1 “Хәлимә”**	1	белем һәм күнекмәләрне практикада куллану.	Укучыларның алган белем һәм күнекмәләрен тикшерү	ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау ШУУГ: үз уңышларың/ уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү	Дәфтәр 39 нчы күнегү	10.11	
27	Хаталар өстендә эш.Үткәннәрне ныгыту.Тест №3	1	катнаш	Матур һәм дөрес язу күнекмәләрен ныгыту	РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	Дәфтәр 40 күнегү	12.11	
28	Сүз төркемнәре. Исем.	1	ныгыту	исем төшенчәсе, мәгънәсе, сораулары	РУУГ: кагыйдә, таблица ярдәмендә бирем үтәлешенең дөреслеген тикшерү КУУГ: сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алу ТБУУГ:төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау	Дәфтәр 44, 45 нче күнегү	14.11	
29	Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.	1	катнаш	Иҗади эш, ялгызлык төшенчәсе, төркемнәре, язылышы уртаклык төшенчәсе, язылышы, алган белемнәрне практикада куллану		88 күнегү хәтердән яз	17.11	
30	Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Сайланма		катнаш			Исем темасына тест биреме	19.11	

	диктант.							
31	Берлек һәм күплек сандагы исемнәр.	1	ныгыту	берлек һәм күплек сан формалары, берлектән-күплек, күплектән-берлек ясау		96 нчы күнегү 47 нче күнегү дәфтәр	21.11	
32	Исемнәрнең килеш белән төрләнеше.	1	ныгыту	Тберлек һәм күплек тартым кушымчалары		Дәфтәр 50 нче күнегү	24.11	
33	Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше	1	яңа белем			Дәфтәр 51 нче күнегү	26.11	
34	Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше.Тест	1	практикада куллану			Тест биремнәре	28.11	
35	Контроль диктант "Хәлимә"	1	ныгыту		ТБУУГ:шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), хикәя төзеп яза; өйрәнелгән тыныш билгеләрен кую	Фигыль турында белемнәрне искә төшер	1.12	
36	Фигыль турында үткәннәрне искә төшерү.	1	ныгыту	фигыль төшенчәсе, мәгънәсе, сораулары, эшне, хәрәкәтне, хәлне белдерүче фигыльләр; җөмләдәге роле	ШУУГ: белү-белмәү чикләрен чамалау ТБУУГ:төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү РУУГ: кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга иярep гамәлләр кылырга; КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү	“Әдәби уку” дәреслегеннән фиг. заманын яз	3.12	
37	Хәзерге заман хикәя фигыль.	1	кабатлау	хәзерге заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, ясалышы, юклык төр кушымчалары, сөйләмдә аларны аера белү		80 бит 11 күнегү Дәфтәр 56 нче күнегү	5.12	
38	Хәзерге заман хикәя фигыль.	1	катнаш			Дәфтәр 57 нче күнегү	8.12	
39	Үткән заман хикәя фигыль.	1	яңа белемнәр формалаштыру	үткән заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, сөйләмдә аларны аера белү		122 нче күнегү 83 бит	10.12	

40	Үткән заман хикәя фигыль.	1	катнаш	билгеле һәм билгесез үткән заман, аның кушымчалары, язылышы		130 нчы күнегү Дәфтәр 60 нчы күнегү 28 бит	12.12	
41	Киләчәк заман хикәя фигыль.	1	катнаш	киләчәк заман хикәя фи-гыльнең белдерелеше, сораулары, кушымчалары; сөйләмдә аларны аера белү		Иҗади эш “Мин волонтер” , “Мин кем булам?” 90 бит	15.12	
42	Киләчәк заман хикәя фигыль.	1	яңа белемнәр формалаштыру	киләчәк заман хикәя фи-гыльнең икенче төре; калын һәм нечкә төрләнеш; тамырда авазлар чиратлашуы		92 бит иҗади бирем	17.12	
43	Боерык фигыль.	1	яңа белемнәр формалаш тыру	Боерык фиг. турында төшенчә. 2, 3 затлары берлек һәм күплек формасы	ТБУУГ: Үтенеч, киңәш бирү, тыю, рөхсәт сорау, кисәтү формаларын итагатле итеп белдерү чараларын дөрес куллану таблицалар кулланып биремнәрне үтәү РУУГ: кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга иярәп гамәлләр кылырга;	142 нче күнегү 96 бит 65 нче күнегү дәфтәр	19.12	
44	Боерык фигыльнең төрләнеше.	1	яңа белемнәр формалаштыру			68 нче күнегү дәфтәр 32 бит	22.12	
45	Боерык фигыль.	1	яңа белем.			Иҗади эш “Кунак булсаң тыйнак бул”, ребус	24.12	
46	Антоним һәм синоним фигыльләр.	1	яңа белем			153 нче күнегү 102 бит	26.12	
47	**Контроль диктант. “Төлке”**		ныгыту	орфограммаларны кулланып, диктант язу, фигыль темасы буенча биремнәрне үтәү	ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау	Тест биремнәре	9.01	

					ШУУГ: үз уңышларың/ уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау			
48	Хаталар өстендә эш. Тест биремнәрен башкару.		ныгыту	Дәреслектәге тест биремнәре эшләнелә.		Дәфтәр 71 нче күнегү 35 бит	12.1	
49	Сыйфат турында үткәннәрне кабатлау. (2 кисәк)	1	ныгыту	Парларда эш, иҗади эш, сыйфат төзелеше, анализлау	ТБУУГ: төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру КУУГ: партадаш күршең белән хезмәттәшлек	Дәфтәр 72-73 нче күнегү	14.1	
50	Сыйфат дәрәҗәләре.	1	ныгыту	Сыйфат дәрәҗәләре төп (гади) , чагыштыру, артыклыккимлек, сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы, аларның дөрес язылышы		Иҗади эш “Минем дустым”	16.1	
51	Сыйфат дәрәҗәләре.	1	белем һәм күнекмәләрне контрольдә тоту			74-76 нчы күнегү дәфтәр, карточка биреме.	19.1	
52	Сыйфатларның җөмләдә аергыч һәм хәбәр булып килүе.	1	Яңа белем	Сыйфатның хәбәр булып килүенә нык игътибар итү		Эш дәфтәре 77, 78 нче күнегү	21.1	
53	Синоним һәм антоним сыйфатлар.	1	катнаш			Иҗади эш. “Батыр кеше бер үлә, куркак кеше көн дә үләр”	23.1	
54	Сочинение язу “Керпе”.	1	ныгыту	Картина буенча сочинение язу	**ТБУУГ:**шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән), хикәя төзеп яза; өйрәнелгән тыныш билгеләрен куя	Дәфтәр 39 бит иҗади бирем	26.1	
55	Үткәннәрне ныгыту.Тест биреме.	1	ныгыту			Тест биремнәре В өлеше	28.1	
56	Зат алмашлыклары.	1	яңа белемнәр формалаштыру	берлек сандагы зат ал-машлыкларын килеш белән төрләндерү; дөрес әйтелеш һәм язылыш	**ТБУУГ:** Зат алмашлыкларының җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге ролен, 1 нче, 2 нче, 3 нче зат алмашлыкларын сөйләшүдә катнашучыларга мөнәсәбәтле рәвештә төркемли,1 нче зат –сөйләүче	84 нче күнегү дәфтәр	30.1	

					үзе,2 нче зат –әңгәмәдәш, 3 зат – әңгәмәдә катнашмаучы икәнен. Алмашлыкларның берлек һәм күплек формаларын, аларның килеш һәм тартым белән төрләнәшен			
57	Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.	1	яңа белемнәр формалаш тыру	берлек сандагы зат ал-машлыкларын килеш белән төрләндерү; дөрес әйтелеш һәм язылыш	ТБУУГ: төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру КУУГ: партадаш күршең белән хезмәттәшлек	Хикәя иҗат ит. “Үзем турында”, “Чаңгы ярышы”	2.2	
58	Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше.	1				Карточка биреме	4.2	
59	Сорау алмашлыклары.	1	Яңа тема	Сорау алмашлыклары турында аңлату		Иҗади эш дәреслек 26 бит	6.2	
60	Сорау алмашлыклары.Тест биремнәре.	1	яңа белем			35 нче күнегү 26 бит	9.2	
61	Аңлатмалы диктант “Аны һәркем ярата”	1	нык ыту		РУУГ:үтелгән орфограммалар кергән текстны, тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп яза	Дәфтәр 42 бит иҗади эш	11.2	
62	Сан турында төшенчә.	1	Яңа белем	Сан түрында беренчел күзаллау тудыру	ТБУУГ:төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү РУУГ: кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга иярен гамәлләр кылырга; ШУУГ: дәреслек геройларына ярдәм итү	Дәфтәрдәге 89 нчы күнегү	13.2	
63	Микъдар саны.	1	Яңа белем	Парларда эш, кагыйдә белән дәлилләү		32 бит иҗади бирем	16.2	
64	Микъдар саны.	1	катнаш	Саннарның телебездә сүз белән дә, цифр белән дә белдерүе		Дәфтәр 91 нче күнегү	18.2	
65	Тәртип саннары.		Яңа тема			Дәфтәр 93 нче күнегү	20.2	
66	Тәртип саннары.Тест	1	нык ыту			50 нче күнегү 36 бит	25.2	

	биремнәре.							
67	Искәртмәле диктант.” Чәүкә”	1	катнаш	орфограммаларны кулланып диктант язу, саннарны табу		Берәр кош яки җәнлек турында проект эше	27.2	
68	Рәвеш турында төшенчә.	**1**	Яңа тема		ТБУУГ:төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру ТБУУГ:рәвешнең-мөстәкыйль сүз төркеме икәнен, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерүен, морфологик яктан төрләнмәгәнен, синтаксик яктан җөмләдә фигыльне, сыйфатны һәм рәвешне дә ачыклап килгәнен белү ШУУГ: дәреслек геройларына ярдәм итү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	54 нче күнегү дәреслек	2.3	
69	Те лдә еш кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы.	1	яңа белем	төрле сүзләр янында килүе; текстта рәвешне таба белү, куллану		Дәфтәр 96, 97 күнегү	4.3	
70	Те лдә еш кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы.	1	ныгыту			Дәфтәр 99 күнегү	6.3	
71	Изложение язу “Ябалак, тавык, аучы”	1	катнаш			Тест биремнәре А өлеше	9.3	
72	Рәвеш темасын ныгыту.Тест биреме.	1	катнаш	хезмәтләрне коррекцияләү; рәвешнең сөйләмдәге әһәмиятен билгеләү, кулланылышын карау		Тест биреме В өлеше	11.3	
73	Кисәкчәләр.	1	катнаш	Кисәкчәләр аларның мәгънәләре кисәкчәләрнең кулланы-лышы, язылышы, аерым сүз булуы; калын һәм нечкә әйтелешле кисәкчәләр	ТБУУГ: кисәкчәләрне кушымчадан аера, таный, калын һәм нечкә әйтелешне билгели, дөрес яза, сөйләмдә куллана РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	64 нче күнегү 46 бит	13.3	
74	Кисәкчәләрнең сөйләмдә роле.Тест биреме.	1	Ныгыту			Дәфтәр 101 күнегү 48 бит	16.3	
75	Бәйлекләр.	1	Яңа тема	хезмәтләрне анализлау, ярдәмче сүз төркеме буларак бәйлек;	ТБУУГ:бәйлекне таный, сөйләмдә куллана һәм дөрес яза	Дәфтәр 103 нче күнегү 49 бит	18.3	

				жөмләдәге роле				
76	Бәйлекләр.	1	ныгыту.	Бәйлекнең җөмләдәге роле		Дәфтәр 106 нчы күнегү	20.3	
77	**Контроль диктант №3 “Сугыш һәм яз”**	1	белем һәм күнекмәләрне практикада куллану	орфограммаларны кулланып диктант язу; грамматик биремне башкару	ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау ШУУГ: үз уңышларың/ уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	Тест биремнәре	23.04	
78	Хаталар өстендә эш.Бәйлек темасын ныгыту.	1	ныгыту	Бәйлекләрнең роле, аларны билгели алу		55 бит иҗади бирем	3.4	
79	Сүзтезмә.	1	Яңа тема	сүзләр бәйләнешен табу	ТБУУГ**:** сүзтезмәләрне, аның иярүче һәм иярүче сүзләрен аера, сорау куя	59бит иҗади бирем сөйлә	6.4	
80	Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше.Аңлатмалы диктант.	1	белем һәм күнекмәләрне практикада куллану.	сүзтезмә төшенчәсе, аларны аера белү, сораулар кую	ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау.	81 нче күнегү 60 бит	8.4	
81	Җөмлә.Җөмләнең баш кисәкләре**.**	1	ныгыту һәм гому-миләштерү	җөмлә төшенчәсе; укылыш, тавыш куелышын тыныш билгесенә карап билгеләү; тасвирлау, фикер йөртү элементлары кертү	ТБУУГ: төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру ТБУУГ: җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен таба, аера, язуда билгели, җөмләдәге сүзләр бәйләнешен ачыклый -җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең узара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен -тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләрне таба -эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш	84 нче күнегү 61 бит	10.4	
82	Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр.	1	Яңа белемнәр			87 нче күнегү 63 бит	13.4	
83	Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.		Яңа белем			90 нчы күнегү 64 бит	15.4	
84	Җөмләнең иярчен кисәкләре.Аергыч.	1	Яңа белемнәр	хезмәтләргә бергәләп бәя бирү, хаталарны төзәтү;		Карточка биреме	17.4	

85	Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.	1	Яңа белем	гади һәм кушма җөмлә төшенчәсен аңлату; тиңдәш кисәкләрне табу, чагыштыру, аеру, куллану	билгеләрен куя -гади һәм кушма җөмләләрне аера КУУГ: тормыш тәҗрибәсен куллану	98 нче күнегү 69 бит, дәфтәр 112 күнегү	20.4	
86	Эндәш сүзләр.Тест биреме.	1	Яңа белем			103 нче күнегү 72 бит	22.4	
87	Гади һәм кушма җөмлә.	1	Яңа белем			113 күнегү дәфтәр	24.4	
88	Гади һәм кушма җөмлә.	1	ныкыту			108 нче күнегү 77 бит	27.4	
89	**Изложение язу. “Кечкенә умартачы”**	1	белем һәм күнекмә-ләрне прак-тикада кул-лану.	орфограммаларны кулланып изложение язу, сүз төркемнәрен билгеләү	РУУГ**:** үтелгән орфограммалар кергән текстны, тиешле тыныш билгеләрен куеп, изложение итеп итеп яза		29.4	
90	Үткәннәрне ныкыту.Тест биремнәре.	1	ныкыту		ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне, белү-белмәү чикләрен чамалау	Дәфтәр 115 күнегү	1.5	
91	Текст.Тема.Текст өлешләре.	1		текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, шулар нигезендә аңа килешле исем кую	ТБУУГ**:** текстның темасын һәм төп фикерен билгели, мәгънәле кисәкләргә, өлешләргә бүлә, кызыл юлны сайлый, текстка исем куя, төрләрен аера, планын төзи, сюжетлы картинага таянып хикәяләр төзи КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	81 бит иҗади бирем “Икмәк үстерү-авыр эш”	4.5	
92	Текст.Тема.Текст өлешләре.	1	Яңа белем			113 нче күнегү 83 бит, 84 бит проект эше	6.5	
93	Сөйләм этикасы.	1	катнаш	әдәпле мөгаләмә таләпләренә туры китереп аралаша белү;			8.5	
94	Сөйләм этикасы.	1	катнаш	язма сөйләм нормаларын, язылыш кагыйдәләрен искә төшерү	ТБУУГ**:** фикерне төгәл, ахырынача, эзлекле итеп җиткерә, дәлилли, дөрес яза,тылсымлы сүзләр телдән, язмача чакыру, тәбрикли	117 нче күнегү дәфтәр	11.5	

95	Хикәяләү, тасвирлау текстлары.	1	ныгыту һәм гому-миләштерү	Һәр абзака исем кую, план төзү,эчтәлек сөйләү,орфограммаларны табу,эчтәлеген язу	КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү РУУГ: гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау	118 нче күнегү дәфтәр	13.5	
96	Хикәяләү, фикерләү текстлары.	1	ныгыту	хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү тибындагы текстларны сөйләмдә куллану;		127 нче күнегү 95 бит	15.5	
97	**Контроль диктант №4 “Җырчы кош”**	1	ныгыту	Ел буена үткән белем һәм күнекмәләрне ныгыту	ТБУУГ: үтелгән орфограммалар кергән текстны, тиешле тыныш билгеләрен куеп, диктант итеп яза	Дәфтәр 119 күнегү	18.5	
98	Хаталар өстендә эш. Сурәтләү һәм хикәяләү текстлары	1	ныгыту	Һәр абзака исем кую, план төзү,эчтәлек сөйләү,орфограммаларны табу,эчтәлеген язу	ТБУУГ**:** алган белемнәрне мөстәкыйль куллана текстның темасын һәм төп фикерен билгели, мәгънәле кисәкләргә, өлешләргә бүлә, кызыл юлны сайлый, текстка исем куя, төрләрен аера, планын төзи, сюжетлы картинага таянып хикәяләр төзи	131 нче күнегү иҗади бирем	20.5	
99	Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту.		ныгыту	Ел буена үткән белем һәм күнекмәләрне ныгыту	РУУГ:Үтелгән кагыйдәләргә нигезләнеп, тест һәм күнегүләр эшләү	136 нчы күнегү 102 бит иҗади	22.5	
100	Үткәнне ныгыту	1	ныгыту	Ел буена үткән белем һәм күнекмәләрне ныгыту		144 нче күнегү 106 бит	25.5	
101	Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту .Тест биремнәре	1	ныгыту	Ел буена үткән белем һәм күнекмәләрне ныгыту.	ТБУУГ**:** алган белемнәрне практикада куллана; эзлеклелекне саклый; тест эшләрен тикшерә, бәяләү	147 нче күнегү 108 бит	27.5	
102	Уку елында өйрәнгәннәрне ныгыту.Йомгак.	1	ныгыту һәм систе-малаштыру			Кагыйдәләрне кабатла.	29.5	

4 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләрендә булачак нәтиҗәләр

-сүзләрдәге орфограммаларны танып, аларның язылышын кагыйдәгә нигезләнеп аңлату;

-үтелгән орфограммалар кергән 75-80 сүзле текстны хатасыз, каллиграфик күчереп һәм ишетеп, тиңдәш кисәкләр янында тиешле тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;

-*дөнья, болыт* тибындагы сүзләргә аваз-хәреф анализы ясау;

-сүзләрне төзелеше ягыннан тикшерү: тамырын һәм кушымчасын табу, кушымчаларның төрен билгеләү, кушма һәм парлы сүзләрне аерып күрсәтү;

-сүзләрне сүз төркеме булу ягыннан тикшерү: исемнең сан, килеш формасын күрсәтү; сыйфатның асыл, нисби төрен, чагыштыру дәрәҗәсен билгеләү; фигыльнең зат-сан, заманын аера белү; һәр сүз төркеменең җөмләдәге функциясен билгеләү;

-тиңдәшле кисәкле гади җөмләгә, составында 2-3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләгә анализ ясау;

-җөмләләрнең әйтелү максаты, интонациясе буенча төрен аеру;

-текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, шулар нигезендә аңа килешле исем кую;

-хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү тибындагы текстларны сөйләмдә куллану;

-әдәпле мөгаләмә таләпләренә туры китереп аралаша белү;

-тасвирлау, фикер йөртү элементлары кергән 90-95 сүзле текстны изложение итеп язу;

-хикәяләү тибындагы сочинение язу;

-сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру: *авыру, аз-маз,ата-ана,ашханә, аңлый,әби-бабай, әверелә, әүвәл,балачак, бәла, берничә, борынгы, вакыйга, ватык, гадәт, гомер, дәвам, җәяү, җепшек, җиләк-җимеш, зинһар,иелә, ихтирам, йомры, кадәр, кием-салым, кулъязма, көнбатыш, көнчыгыш, көрәшче, кыйммәтле, мал-туар, мәйдан, мәкалә, могҗиза, мөстәкыйль, нәкъ,охшаш, очсыз, өем, өчпочмак, пәрәвез, рәссам, савыт-саба, сәнгать, сөңге, сурәт, табиб, табигый, таләп, тәкъдим, тәмам, тирә-як, төер, туп-туры, тынгылык, чүп-чар, шагыйрь, шәфәкъ, шыңшый, эшчән, юеш, юньле, юучы, ямьле, ямь-яшел, япь-яшь*

Укучыларның белемен бәяләү системасы

Укучыларның эшчәнлеген бәяләү белемнәрне үзләштерүне тикшерүдәе аларны гамәлдә куллана белүгә күчерелә.

Мәгълүмат чыганаклары:

-укучыларның эшләре

-танып белү процессының барышы;

-статистикага нигезләнгән мәгълумат;

-тестлар уздыру нәтиҗәләре;

-портфолио;

Тикшерү алымнары:

-күзәтүләр;

-мөстәкыйль контроль эшләр;

-укучыларның әзер җавапны табуы, ирекле кыскача җаваплары; ачык җавап, үз-үзеңне тикшерүх өчен сораулар куя белү.

Бәяләү критерийлары:

--җавапларның дөрес булуы;

-грамматика кагыйдәләрен куллана белүдә шәхси үсеш;

-әйтмә һәм язма сөйләмнең төгәллеге һәм сәнгатьлелеге үсешендә югарырак баскычка күтәрелү;

-җавапның, уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән продуктның сыйфаты; нигезләмәләрнең уйланган булуы;мөстәкыйль әйтелгән гипотезаның, аңлатмаларның, язма сөйләм модельләренең дөрес төзелгән булуы, сөйләмнең максатчан оештырылуы.

Уку әсбабы

1.Татар теле 1 кисәк, 2 кисәк дәреслек 4 сыйныф И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел

2. И.Х Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова Методик әсбаб. “ Мәгариф- вакыт” нәшрияты 2014 ел

3. Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар. 1-11 нче сыйныфлар Казан Татар. китап. нәшрияты 2011 ел

4. Диктантлар җыентыгы

5. 1-4 сыйныфлар өчен язма эшләр Казан 2009